Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

11 май 2018 ел №239

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
Районының 2008 елның 31 октябрендәге
“Аерым эшчәнлекләрнең керемнә бердәм
салым төре буларак салым системасын гамәлгә
кертү, 2009 елның 1 гыйнварыннан аерым
эшчәнлекләрнең керемнә бердәм салымның
төп керемгә К2 корректлаучы коэффициентын
һәм эшчәнлек төрләрен билгеләү турында” 271 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, Россия Федерациясенең Салым кодексының 26.3 бүлегенә туры китереп, 2018 елның 30 мартындагы № 33м хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча йомгакны карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының 2008 елның 31 октябрендәге “Аерым эшчәнлекләрнең керемнә бердәм салым төре буларак салым системасын гамәлгә кертү, 2009 елның 1 гыйнварыннан аерым эшчәнлекләрнең керемнә бердәм салымның төп керемгә К2 корректлаучы коэффициентын һәм эшчәнлек төрләрен билгеләү турында” 271 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2010 елның 26 маендагы №400, 2011 елның 28 апрелендәге №76, 2011 елның 28 июлендәге №92, 2011 елның 22 сентябрендәге №117, 2012 елның 28 ноябрендәге №243, 2016 елның 30 ноябрендәге №137 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 нче пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

“3. Бердәм салым түбәндәге эшмәкәрлек төрләренә карата кулланыла:

1) көнкүреш хезмәте күрсәтү. Эшчәнлек төрләре коды икътисадый эшчәнлекнең төрләре Бөтенроссия классификаторына туры китереп, хезмәт күрсәтү кодлары, көнкүреш хезмәтенә кертелгән Бөтенроссия продукция классификаторы эшчәнлегенең төрләренә туры китереп, Россия Федерациясе хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;

2) ветеринария хезмәте күрсәтү;

3) автотранспорт чараларын төзекләндерү, техник тикшерү үткәрү, юу буенча хезмәт күрсәтү;

4) автотранспорт чаралары тукталу урынына вакытлыча куллануга урын бирү, шулай ук автотранспорт чараларын түләүле тукталу урынында саклау (штраф стоянкалардан кала) хезмәте күрсәтү;

5) хезмәт күрсәтү өчен хосусый милектә яки башка хокукта автотранспорт чаралары 20 дән артмаган, пассажирлар һәм йөк күчерү хезмәте күрсәтү;

6) сәүдә оештыру өчен һәр объектка мәйданы 150 квадрат метрдан артмаган залы булган кибет һәм павильоннар аша ваклап сату, аңа карата бердәм салым кулланылмый;

7) стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары, үз сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша ваклап сату;

8) җәмәгать туклану оешмасының һәр объектының 150 квадрат метрдан артык халыкка хезмәт күрсәтү залы аша җәмәгать туклану хезмәте күрсәтү. Бу караның максатында, җәмәгать туклану оешмасының һәр объектына халыкка хезмәт күрсәтү өчен 150 квадрат метрдан артык мәйданлы залы булган җәмәгать туклану оешмалары эшмәкәрлек эшчәнлеге төре буларак танылa, аңа карата бердәм салым кулланылмый;

9) объектларының халыкка хезмәт күрсәтү өчен заллары булмаган җәмәгать туклану оешмалары аша җәмәгать туклану хезмәте күрсәтү;

10) реклама төзелмәләрен кулланып тышкы рекламаны тарату;

11) транспорт чараларының эчке һәм тышкы йөзлекләрен реклама урнаштыру өчен куллану;

12) һәр объектында хезмәт күрсәтү өчен вакытлыча урнаштыру һәм яшәү өчен 500 квадрат метрдан артмаган мәйданлы бинаны кулланып, вакытлыча урнаштыру һәм яшәү хезмәте күрсәтү оешмалары һәм эшмәкәрләр;

13) стационар сәүдә челтәрләрендә урнашкан, сәүдә заллары булмаган, стационар булмаган сәүдә челтәрләре объектлары, шулай ук килүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен заллары булмаган җәмәгать туклану оешмалары объектларына вакытлыча ия булу яки куллану хезмәте күрсәтү;

14) стационар һәм стационар булмаган сәүдә челтәрләре объектларын, шулай ук җәмәгать туклану оешмалары объектларын урнаштыру өчен җир бүлемтекләренә вакытлыча ия булу, кулануга бирү хезмәте күрсәтү.

Бердәм салым карарның 3 нче пунктында күрсәтелгән эшмәкәрлек эшчәнлеге төрләренә карата түбәндәге очракларда кулланылмый:

- шушы төр эшчәнлекне гади ширкәт (уртак эшчәнлек турында килешү) яки милек белән ышаныч килешүе буенча идарә итү очрагы;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 83 нче маддәсе буенча эре категориясенә караган салым түләүчеләр тарафыннан мондый эшчәнлек төрләрен күрсәтүче очраклар;

- бу төр эшчәнлеккә карата Россия Федерациясенең Салым кодексының 33 нче бүлегенә туры китереп муниципаль берәмлектә сәүдә җыемы билгеләнгән булуы.

Карарның 3 нче пункты 6-9 нчы подпунктларында күрсәтелгән эшмәкәрлек төрләренә бердәм налог кулланылмый. Бу эшмәкәрлек төрләре Салым кодексының 26.1 бүлегенә туры китереп, бердәм авыл хуҗалыгы салымын түләүгә күчкән, үзләре беренчел эшләп чыгарган продукцияне җәмәгать туклану оешмалары һәм сәүдә оешмалары аша гамәлгә ашыручы оешма һәм шәхси эшмәкәрлек.

1.2. карарның 4 нче пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

“4.Бердәм салымга күчүгә хокуклары булмаган очраклар:

1) Үткән календарь елда башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан кабул ителгән, статистика өлкәсендә вәкаләтле, уртача хезмәткәрләр саны 100 дән артмаган оешма һәм шәхси эшмәкәрлек.

Бу пунктчаның положениеләре үз эшчәнлекләрен 1992 елның 19 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә кулланучылар коперациясе (кулланучылар җәмгыяте, аларның берләшмәләре)” турындагы 3085-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә алып баручы кулланучылар кооперациясе оешмаларына карата, шулай ук үз эшчәнлекләрен шушы законга нигезләнеп алып баручы, бердәнбер оештыручылары кулланучылар җәмгыяте һәм аларның берләшмәләре булган хуҗалык җәмгыятьләренә карата кулланылмый.

2) Башка оешмаларның катнашу өлеше әлеге оешмада 25 процентттан артык булган оешмалар. Күрсәтелгән чикләү устав капиталы тулысынча инвалидлар җәмгыяте оешмалары кертеменнән торган, эшчеләре арасында инвалидларның уртача саны 50 проценттан кимрәк, ә аларның хезмәт хакы фонды өлеше 25 проценттан кимрәк булмаган оешмаларга карата, үз эшчәнлекләрен 1992 елның 19 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә кулланучылар коперациясе (кулланучылар җәмгыяте, аларның берләшмәләре)” турындагы 3085-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә алып баручы кулланучылар кооперациясе оешмаларына карата, шулай ук үз эшчәнлекләрен шушы законга нигезләнеп алып баручы, бердәнбер оештыручылары кулланучылар җәмгыяте һәм аларның берләшмәләре булган хуҗалык җәмгыятьләренә карата җәелдерелми;

3) Әгәр җәмәгать туклану хезмәте күрсәтү бирелгән оешмалар эшчәнлеге процессының аерылгысыз өлеше булса һәм бу хезмәтләр турыдан-туры күрсәтелгән оешмалар тарафыннан күрсәтелсә, карарның 3 нче пунктының 8 нче пунктчасында күздә тотылган җәмәгать туклану хезмәте буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге өлкәсендә белем бирү оешмалары, медицина оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары;

4) Әлеге карарның 3 нче пункты 13, 14 пунктчаларында күрсәтелгән автозаправка һәм газозаправка станцияләренә вакытлыча куллануга яки куллануга бирү өлкәсендә эшмәкәрлек эшчәнлеге төрлоәрен күрсәтүче шәхси эшмәкәрләр һәм оешмалар;

1.3. Әлеге карарның беренче кушымтасында:

1.3.1. 7 нче пунктта “Эшчәнлек төрләре” баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Кибет һәм павильоннар аша һәр сәүдә объектының сәүдә заллары мәйданы 150 квадрат метрдан артмаган ваклап сату. Әлеге карарның максаты буенча, кибет һәм павильоннар аша һәр сәүдә объектының сәүдә заллары мәйданы 150 квадрат метрдан артык ваклап сату, бердәм налог кулланылмый торган эшмәкәрлек эшчәнлеге төре булып танила.”

1.3.2. 10 нчы пунктта “Эшчәнлек төрләре” баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10. Җәмәгать туклану оешмасының һәр объекты буенча хезмәт күрсәтү залларының мәйданы 150 квадрат метрдан артмаган җәмәгать туклану оешмасыны объектлары аша җәмәгать туклану хезмәте күрсәтү. Әлеге карарның максаты буенча, җәмәгать туклану оешмасының һәр объекты буенча хезмәт күрсәтү залларыныҗ мәйданы 150 квадрат метрдан артык җәмәгать туклану оешмасыны объектлары аша җәмәгать туклану хезмәте күрсәтү, бердәм налог кулланылмый торган эшмәкәрлек эшчәнлеге төре булып танила.”

1.3.3. 16 нчы пунктта “Эшчәнлек төрләре” баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16. Вакытлыча урнаштыру һәм яшәү өчен һәр объектының мәйданы 500 квадрат метрдан артмаган биналарны кулланып, вакытлыча урнаштыру һәм яшәү хезмәте күрсәтүче оешмалар һәм эшмәкәрләр”.

2. Әлеге карар 2018 нче елның 1 нче июлендә үз көченә керә, ләкин “Альметьевский вестник” газетасында басылып чыкканнан соң бер ай вакыттан иртәрәк түгел.

3. Район башкарма комитетның хокук идарәсенә (Шщйхулова Ф.Х.) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча район Советының даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Муниципаль район башлыгы А.Р.Хәйруллин